ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУЛЕГАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЛӘГӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.02.2020 Күләгәш авылы № 4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлегендә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлегендә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе Ю.Н. ВАСИЛЬЕВ

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль айоны
Күләгәш авыл җирлеге
башкарма комитетының
06.02.2020 ел, № 4
карары белән

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлегендә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлегендә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне (алга таба - мөрәҗәгатьләрне) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлегенә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау язмача, электрон хәбәрләр рәвешендә, шулай ук Интернет-кабул итү, гражданнарны шәхси кабул итү барышында һәм телефон аша мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып башкарыла.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау чоры елга ике тапкыр тәшкил итә: ярты ел эчендә һәм узган елда.

4. Һәр яртыеллык нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлегенә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау өчен җаваплы зат гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерә.

5. Анализ үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

- кергән, адресланган һәм каралган мөрәҗәгатьләр, шул исәптән телдән һәм язма мөрәҗәгатьләр саны, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләрне дә кертеп;
- мөрәҗәгатьләр структурасы һәм тематикасы;
- шәхси кабул итү өчен җаваплы затларның шәхси кабул итүендә кабул ителгән гражданнар саны;
- мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар буенча кабул ителгән чаралар (булган очракта).

6. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерелгән анализ елга ике тапкыр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru урнаштырыла.